СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.НовыйКырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел** **№1**

**Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылында Яңа Кырлай авылы, Татарстан урамы, 20а йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 05 ноябренә 09 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылында Яңа Кырлай авылы, Татарстан урамы, 20а йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 05 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә
3. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылында Яңа Кырлай авылы, Татарстан урамы, 20а йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 05 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә
4. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылында Яңа Кырлай авылы, Татарстан урамы, 20а йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан

файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 05 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә

5.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Яшел, Дуслык, Яшьләр урамында яшәүчеләр

2нче этап: Татарстан урамының 1 йортыннан 42 йортына кадәр яшәүчеләр.

3нче этап: Татарстан урамының 44 йортыннан 90 йортына кадәр яшәүчеләр.

4 нче этап: Тукай урамында яшәүчеләр.

6. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш,300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау, Яшьләр урамы-400м, Дуслык урамы-300м.

-урамның юл полотносында чокырларны тигезләү, Тукай урамының 52 йортыннан 95 йортына кадәр.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

7. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 3 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН1609012702